**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.02.2021 г. Казань № 18од

Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/62 номерлы боерыгы белән расланган исемлеген үзгәртү турындагы тәкъдимен исәпкә алып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/62 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының

2017 елның 21 июлендәге 01-02/79 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган исемлегенә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1 | Әлмәт шәһәре | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Ленин ур., 98 нче йорт | Ленин урамындагы 98 нче йорт янындагы территория, «Нефтьче» мәдәният йорты янында («Нефтьче» мәйданы) |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Белоглазов ур., 60 нчы йорт | Белоглазов урамындагы «Юбилейный» спорт сарае белән янәшә урнашкан 60 нчы йорт янындагы территория («Юбилейный» спорт сарае мәйданы) |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ. | шәһәр мәйданы территориясе |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһ., Р. Фәхретдин ур, 13 нче йорт | Р. Фәхретдин урамында урнашкан 13 нче йорт янындагы территория (Хәтер мәйданы) |
| | | Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһ., Совет ур. | Толстой урамындагы 2 нче йорт каршындагы территория, яшел үсентеләр янында». |

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М. Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин